**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 июнендәге 2707 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә «Төнге Казан – 2024» җиңел атлетика чарасын уздыру һәм чараны әзерләү һәм уздыру чорына транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары нигезендә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, Казан шәһәрендә җиңел атлетиканы популярлаштыру максатларында, 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2007 елның 8 маендагы 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» федераль законнарга һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәрендә «Төнге Казан – 2024» җиңел атлетика чарасына әзерләнү һәм аны уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләргә:

- 2024 елның 27 июлендә 23:30 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 00:40 сәгатькә кадәр Кремль дамбасында (Батурин урамыннан Декабристлар урамына кадәрге юнәлештә, хәрәкәт тулысынча чикләнә);
- 2024 елның 27 июлендә 23:30 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 00:40 сәгатькә кадәр Декабристлар урамы буенча (Кремль дамбасыннан С.Хәким урамына кадәрге юнәлештә, хәрәкәт тулысынча чикләнә);

- 2024 елның 27 июлендә 23:30 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 00:40 сәгатькә кадәр Декабристлар урамы буенча (С.Хәким урамыннан Кремль дамбасына кадәрге юнәлештә, хәрәкәт тулысынча чикләнә);

- 2024 елның 27 июлендә 23:30 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 01:00 сәгатькә кадәр Кремль дамбасында (Декабристлар урамыннан Кремль яр буена кадәрге юнәлештә, хәрәкәт тулысынча чикләнә);

- 2024 елның 27 июлендә 23:00 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 01:30 сәгатькә кадәр Кремль яр буенда (Батурин урамыннан Сәетгалиев урамына кадәрге юнәлештә, хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 27 июлендә 23:00 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 01:30 сәгатькә кадәр Батурин урамы буенча (Федосеев урамыннан Кремль яр буе урамына кадәрге юнәлештә, хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 27 июлендә 23:00 сәгатьтән 2024 елның 28 июлендә 01:30 сәгатькә кадәр Ташаяк урамыннан Кремль дамбасына кадәрге автомобиль юлы буйлап (Меңьеллык мәйданы), хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) әлеге чараны әзерләүдә һәм уздыруда ярдәм күрсәтергә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) транспорт предприятиеләренә юллар ябылу һәм җәмәгать транспорты маршрутлары үзгәрү турында хәбәр итәргә, дистанция маршруты буенча юл билгеләрен урнаштыруны, демонтажлауны, каплауны һәм каплавычыннан арындыруны килештерергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен уздыру графигына төзәтмәләр кертергә, вакыйгага әзерләнгәндә керү юлларын һәм транспорт парковкасы урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чараны уздыру урыннарына якын урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, чараны уздыру тәмамланганнан соң, аларны җыештыруны тәэмин итәргә, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре белән берлектә йөк техникасы белән юлларны ябу буенча ярдәм күрсәтүне оештырырга;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләренә (В.В.Жаворонков, А.И.Салихов, Р.Х.Шәмсетдинов, Р.Р.Фәтхетдинов) әлеге карарның 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталары нигезендә юлларны ябу өчен йөк техникасы бүлеп бирергә;

1.6. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) чараны әзерләү һәм уздыру урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, Казан шәһәренең югарыда күрсәтелгән урам-юл челтәре участоклары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте иминлеге үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (В.С.Филатов) әлеге чарада катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне (шартнамә нигезендә) тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәр Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) массакүләм мәгълүмат чаралары аша спортчылар хәрәкәте вакытында күрсәтелгән участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү кертелүе турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта

Юлларны ябу өчен йөк техникасын урнаштыру схемасы



2 номерлы кушымта

Транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү схемасы

